ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘСӘДЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ
423753,Мәсәде авылы,
Нефтяников ур.,18нче йорт
Тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ МАСАДИНСКО
СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛ
НОГО РАЙОНА
423753,деревня Масады,
ул.Нефтяников,дом 18,
тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

24 октябрь 2024 ел № 9

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Мәсәде авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 21 октябрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елны 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 1 октябрендәге 1360 номерлы карары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципал районы Мәсәде авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Мәсәд авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Мәсәде авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез ди тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 2 октябрендәге 20 номерлы карарына (17.07.2020 елдан 14 номерлы, 07.10.2024 елда 7номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрн кертергә:

1.1 **1 бүлегенең 5 пунктында**:

а) **3 пунктчада** "хисаплылыктан өземтә" сүзләрен "белешмә" сүзен алмаштырырга.;»

б) **4 пунктчада** "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160_1 статьясы нигезенд бюджетка түләүләр, алар буенча пеналар һәм штрафлар буенча дебитор бурычлары түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыр Регламентында каралган"сүзләрен өстәргә.;

в) **5 пунктчада** җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;";

түбәндәге эчтәлекле **абзац өстәргә**:

"гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.".;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Т.Гатин

Масадинский сельский исполнительный комитет